ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печище авылы,
422592

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

18.12.2023 — 152

### Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы нигезендә Октябрьский авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенында кабул ителгән N 1, 23.10.2022 ел, №2, 23.10.2022 ел, № 3 26.10.2022 ел һәм № 4 27.10.2022 ел карарларын гамәлгә ашыру максатларында Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

ТР Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы — Ш.Р. Азизов

Октябрьский авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2023
елның 18 декабреннән 152
номерлы карарына

1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә
гражданнардан үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 1.01.2024 елдан 25.03.2024 елга кадәр гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары.

4. Түләүләр күләме гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:
а) уку йортлары студентлары,
б) күп балалы гаиләләр.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.
Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки кечерәйтелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар түләүләрне физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисаплар башкару хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/. сылтама буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша күчерү юлы белән башкара ала.

8. Түләү фактын раслау булып керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Октябрьский авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2023
елның 18 декабреннән 152
номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү турында

Түләүченең Ф.И.А.и.
____________________________________________________________________
Адрес: ___________________________________________________________
___________________________________________________________ нигезендә
сезгә ______ кадәр чараларны гамәлгә ашыру өчен _____ күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча:
______________________________________________________________бер тапкыр түләү түләргә кирәк.

Алучының банкы БИК ____________________________________________
Сч. № __________________________________________________
Алучы __ Сч. № ________________________________________
ИНН ___________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________________ОКАТО _____________________

Түләү билгеләү
_______________________________________________________________________

Җитәкче ________________________________________________
М. у. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)
- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне бюджетка түләү турында
__________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.

Түләүченең Ф.И.А.и. _____________________________
Адрес: ________________________________________________

Алдым "__" ___________________ 20____ ел ___________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Әгәр хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырыла икән, киселә торган өлеше тутырыла һәм Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.